ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«8 статья. **Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган җирләрдә урнашкан түләүле парковкалар түләүсез файдаланыла торган аерым көннәрне һәм тәүлек вакытын билгеләү**

1. Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган җирләрдә урнашкан түләүле парковкалар түбәндәге очракларда түләүсез файдаланыла:

1) эш көннәрендә һәм шимбә көннәрендә җирле вакыт буенча 21 сәгать 00 минуттан алып 7 сәгать 00 минутка кадәр;

2) транспорт чарасы 15 минуттан да күбрәк булмаган вакытка туктап торганда;

3) ял көннәрендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә.

2. Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган җирләрдә урнашкан түләүле парковка хуҗасы әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында

билгеләнгән мондый түләүле парковка түләүсез файдаланыла торган вакытны арттырырга хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 25 июнь
№ 34-ТРЗ